| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КИЕКЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Киекле ав. КАРАР

«09» ноябрь 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 21 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Клуб урамы, 3нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Кизләү авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатыннан су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- Кизләү авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);
- Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

авыл җирлегенең торак пунктларындагы урамнарны, территорияләрне, Киекле авылындагы ике зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, коймаларны буяу);

- Кизләү авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Кизләү авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Кизләү авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кизләү авылының мәгълүмат стендларында халык җыены үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы. Л.И.Кашапова